ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Мира 12, г. Елабуга, 423603

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Тынычлык пр.12, Алабуга шәһәре, 423603

тел.(85557) 30832, факс.(85557)34211, E-mail: rik_emr@mail.ru, сайт: www.elabugacity.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.05.2021 № 618

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 1287 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 1287 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Физик культура һәм спорт» бүлегенең программа чаралары исемлегендәге 2 нче бүлекчәнең 18, 19 пунктларын түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| № | Эшләрнең (чараларның) төп этаплары | Башкаручылар | Финанслау күләме (мең сумнарда) | | | Башкару вакытлары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 | 2022 | 2023 | |
| 18 | Муниципаль спорт мәктәпләренең спорт командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм | АМР БК спортны үстерү секторы | 479,8 | - | - | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында (А (ярдәмче) төркеме) спорт әзерлеге һәм катнашуы программаларын гамәлгә ашыру; | | | | | |
| 19 | Муниципаль спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алу | АМР БК спортны үстерү секторы | 687,3 | - | - | |

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «2021-2023 елларга Алабуга муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы чараларын үтәү өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов